Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Бишмунча авыл Советы
КАРАРЫ

9 март 2021 ел №19

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Бишмунча авыл җирлеге бюджетының үтәлеше һәм аның тышкы тикшерүе турында еллык хисапны тапшыру, карау һәм раслау тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 264.5 статьясы нигезендә,

Бишмунча авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Бишмунча авыл җирелеге бюджетының үтәлеше һәм аның тышкы тикшерүе турында еллык хисапны тапшыру, карау һәм раслау тәртибен расларга (1 нче кушымта).

2. Әлеге карарны Бишмунча авылы, Совет урамы, 57 нче а йорт, Кама-Елга авылы, Кама-Елга урамы, 26 а йорт, Бакчасарай авылы, Җиләкле урамы, 1 йорт, Ак-Чишмә авылы, Ак-Чишмә урамы, 1 йорт йорт территориясендә урнашкан махсус стендларда халыкка игълан итәргә, шулай ук «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» (PRAVO.TARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка игълан иткәннән соң) үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Бишмунча авыл җирелеге башлыгына йөкләргә.

Бишмунча авыл
җирлеге башлыгы Р.Г.Фазлыев

Татарстан Республикасы Әлмәт
муниципаль районы Бишмунча
авыл Советының 2021 елның
9 мартындагы 19 номерлы
карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Бишмунча авыл җирлеге бюджетының үтәлеше һәм аның тышкы тикшерүе турында еллык хисапны тапшыру, карау һәм раслау тәртибе

1. Гомуми нигезләмә

1.1. Әлеге Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Бишмунча авыл җирлеге бюджетының үтәлеше турында еллык хисапны тәкъдим итү, карау һәм раслау тәртибе Россия Федерациясе Бюджет Кодексы нигезендә эшләнгән.

1.2. Әлеге Тәртип кысаларында финанс елы өчен хисап Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Бишмунча авыл җирлеге бюджетының үтәлеше турында еллык хисапны (алга таба текст буенча - Тәртип, Җирлек) тапшыру, карау һәм раслау кагыйдәләре һәм вакытлары билгеләнә.

2. Авыл җирлеге
бюджет үтәлеше турында финанс елы өчен
еллык хисапны тышкы тикшерү

2.1. Авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында еллык хисап Җирлек Советында каралганчы тышкы тикшерү узарга тиеш, ул бюджет акчалары баш администраторларының бюджет хисабын тышкы тикшерүне һәм бюджет үтәлеше турында еллык хисапка бәяләмәне үз эченә ала.

Тышкы тикшерү составы, билгеләнгән рәвешләргә туры килүе, бюджет хисабы күрсәткечләренең дөрес булуы, еллык бюджет хисаплылыгын тикшерү буенча мәҗбүри контроль гамәлләр системасыннан гыйбарәт.

2.2. Җирлек бюджетының үтәлеше турында еллык хисапны тышкы тикшерү, Россия Федерациясе Бюджет Кодексы таләпләрен үтәп һәм федераль законнарда билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Контроль-хисап палатасы (алга таба - Контроль-хисап палатасы) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2.3. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Бишмунча авылы Башкарма комитеты (алга таба - Башкарма комитет) агымдагы елның 1 апреленнән дә соңга калмыйча җирлек бюджеты үтәлеше турында еллык отчетны тапшыра. Җирле бюджет үтәлеше турында еллык хисапка бәяләмә әзерләү бер айдан да артмаган срокта уздырыла.

Бюджет акчаларының баш администраторлары агымдагы финанс елның 15 мартыннан да соңга калмыйча еллык бюджет хисабын тапшыра.

Тышкы тикшерүне гамәлгә ашырганда Контроль-хисап палатасы «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең Контроль-хисап

органнары эшчәнлеген оештыруның һәм аларның гомуми принциплары турында» 2011 елның 07 февралендәге 6-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Контроль-хисап палатасы тарафыннан эшләнгән һәм расланган тышкы муниципаль финанс контроле стандартларына нигезләнә.

2.4. Контроль-хисап палатасы бюджет акчалары баш администраторларының еллык бюджет хисабы күрсәткечләрен исәпкә алып, Җирлек бюджеты үтәлеше турында хисапка бәяләмә әзерли.

2.5. Җирлек бюджетының үтәлеше турында еллык хисапка бәяләмә Контроль-хисап палатасы тарафыннан бер үк вакытта Җирлек Советына һәм Башкарма комитетка юллама белән тәкъдим ителә.

2.6. Җирлек бюджетының үтәлеше турындагы еллык хисапка Контроль-хисап палатасы бәяләмә алганнан соң Финанс-бюджет палатасы Җирлек Советының хисап финанс елы өчен авыл җирлеге бюджетының үтәлеше турындагы еллык хисабын раслау турындагы карары проектын әзерли.

## 3. Җирлек бюджеты үтәлеше турында еллык хисап бирү

3.1. Җирлек бюджетының үтәлеше турында еллык хисап Башкарма комитет тарафыннан Җирлек Советына агымдагы елның 1 маеннан да соңга калмыйча тапшырыла.

Бюджет үтәлеше турында еллык хисапта Россия Федерациясенең бюджет классификациясе нигезендә бюджет дефицитын финанслау керемнәре, чыгымнары һәм чыганаклары буенча бюджет үтәлеше турында мәгълүматлар бар.

3.2. Җирлек бюджетының үтәлеше турында еллык хисап белән бер үк вакытта Җирлек Советына түбәндәгеләр тапшырыла:

- бюджет һәм бюджет хисаплылыгы үтәлешенә анализ булган аңлатма һәм муниципаль биремне үтәү турындагы белешмәләр һәм (яисә) бюджет ассигнованиеләрен файдалануның башка нәтиҗәләре;
- хисап финанс елында авыл бюджетының үтәлеше турында авыл Советы карары проекты;
- Җирлек бюджеты үтәлеше турында башка бюджет хисабы;
- Россия Федерациясенең бюджет законнарында каралган башка документлар.

3.3. Бюджет хисаплылыгы составына Россия Федерациясе Финанс министрлыгының «Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары үтәлеше турында еллык, квартал һәм айлык хисаплылык төзү һәм тапшыру тәртибе турында инструкцияне раслау хакында» 2010 елның 28 декабрендәге 191н номерлы боерыгы белән расланган рәвешләр буенча хисаплар керә, шул исәптән:

- бюджет үтәлеше турында хисап;
- бюджет үтәлеше балансы;
- эшчәнлекнең финанс нәтиҗәләре турында хисап;
- акча чараларының хәрәкәте турында хисап;
- бюджет үтәлеше турындагы хисапка аңлатма язуы.

3.4. Россия Федерациясенең бюджет законнарында каралган башка документларга түбәндәгеләр керә:

- хисап финанс елында авыл Башкарма комитетының резерв фондының бюджет ассигнованиеләреннән файдалану турында хисап;
- хисап финанс елында авыл җирлегенең муниципаль программаларын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итүгә каралган авыл җирлеге бюджетының бюджет ассигнованиеләреннән файдалану турындагы белешмәләр;

- Россия Федерациясенең бюджет законнарында каралган башка документлар.

4. Җирлек бюджеты үтәлеше турында еллык хисапны карау

4.1. Авыл Советы тарафыннан каралганчы, авыл җирлеге бюджетының үтәлеше турында еллык хисап Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Бишмунча авыл җирлегенең гавами тыңлаулар үткәрү буенча нигезләмә нигезендә гавами тыңлауларга чыгарыла.

4.2. Авыл Советы авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында еллык хисапны караганда авыл җирлеге бюджеты үтәлеше буенча вәкаләтле вазыйфаи затның докладын тыңлый.

4.3. Бюджет үтәлеше турында еллык хисапны карау нәтиҗәләре буенча авыл Советы җирлек бюджетының үтәлеше турындагы карарны раслау яки кире кагу турында карар кабул итә.

Авыл Советы тарафыннан җирлек бюджетының үтәлеше турында карар кире кагылган очракта, ул күрсәткечләрне дөрес чагылдырмау яки тулысынча кире кагу фактларын бетерү һәм бер айдан да артмаган срокка кабат тапшыру өчен кайтарыла.

5. Җирлек бюджеты үтәлеше турында еллык хисапны раслау

5.1. Авыл Советы тарафыннан җирлек бюджетының үтәлеше турындагы еллык хисапны карау нәтиҗәләре буенча хисап финанс елына җирлек бюджетының үтәлеше турында карар кабул иткәндә, күрсәтелгән карарда авыл җирлеге бюджеты керемнәренең, чыгымнарының һәм дефицитының (профицитының) гомуми күләме күрсәтелә.

5.2. Хисап финанс елы өчен авыл җирлеге бюджетының үтәлеше турында еллык хисапны раслау турында авыл Советы карарына аерым кушымталар белән түбәндәге күрсәткечләр раслана:

- бюджетлар керемнәре классификациясе кодлары буенча авыл җирлеге бюджеты керемнәре;
- авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының ведомство структурасы буенча бюджет чыгымнары;
- бюджетлар чыгымнары классификациясенең бүлекләре һәм бүлекчәләре буенча авыл җирлеге бюджеты чыгымнары;
- бюджетлар кытлыкларын финанслау чыганаклары классификациясе кодлары буенча бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары.

Авыл җирлеге бюджетын үтәү турындагы карар белән шулай ук РФ БК, Татарстан Республикасы законы, авыл Советының җирлек бюджетын үтәү турындагы карары белән билгеләнгән башка күрсәткечләр раслана.

Бишмунча авыл
җирлеге башлыгы Р.Г.Фазлыев